СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.09.2023 Баулы шәһәре № 213

2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы
Баулы муниципаль районы Советы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
“Баулы муниципаль районы” муниципаль
берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 7 апрелендәге 47 номерлы Баулы муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

6 статьяның 1 пунктында:

26) пунктчада “торак пункт территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук” сүзләрен төшереп калдырырга;

36) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36) муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру, аз санлы җирле халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын гамәлгә ашыру, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен, милләтара (этникара) конфликтлар профилактикасын тәэмин итү;»;

41 пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«41) тирә-яктагы мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый һәм мондый зыянны торак пункт милкендәге җир участоклары чикләрендә урнашкан территорияләргә карата бетерүне оештыра.»;

12 статьяның 12) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) территориаль иҗтимагый үзидарәсе;»;

10 пунктын 5) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«5) проект инициаторлары буларак инициативалы проектны тәкъдим итә алалар»;

17 статьяда:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ачык тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат, аны уздыру вакытын һәм урынын билгеләп, шулай ук ачык тыңлауларга чыгарылачак муниципаль норматив хокукый акт проекты, ачык тыңлаулар уздырыр алдыннан 7 календарь көненнән дә соңга калмый, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында бастырылып чыгарылырга (игълан ителергә), шулай ук Баулы муниципаль районы сайтында һәм “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырылып чыгарылырга тиеш»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Ачык тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты бастырылып чыккан (игълан ителгән) көннән алып, районда яшәүчеләр, район Башлыгына ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акты проекты яки сораулары буенча тәкъдимнәрен һәм искәртүләрен җибәрергә хокуклы, шул исәптән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да».

Тәкъдимнәрне һәм искәртүләрне җибәрү, ачык тыңлаулар уздырыр алдынан 2 эш көне кала, туктатыла.

Район Башлыгы килеп ирешкән тәкъдимнәрне һәм искәртүләрне гомумиләштерүне һәм ачык тыңлауларда катнашучыларга җиткерүне оештыра»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында бастырылып чыгарылырга (игълан ителергә), шулай ук Баулы муниципаль районы сайтында һәм “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында, ачык тыңлаулар уздырылганнан соң 5 календарь көннән дә калмый урнаштырылырга тиеш.”;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе, район Советы белән расланган, ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән билгеләнә.»;

28 статьяда:

7 пунктның б) подпунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазифалы кешесе, муниципаль вазыйфаны биләүче башка кеше, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы “Россия Федерациясендә  җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне һәм бурычларны  үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә һәм коррупциягә каршы тору максатыннан башка федераль законнар белән, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затлардан бәйсез булган шартлар тикшерүе тарафыннан “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылса икән».»;

31 статьяның 15) пунктчасын төшереп калдырырга;

37 статьяның 1 пунктын  13 пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«13) депутатның, алты ай дәвамында, җитди сәбәпләрсез, район Советының барлык утырышларында булмавы»;

38 статьясы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«38 Статья. Район Советында фракцияләр

1. Кандидатлар исемлеге составында сайланган, сәяси партияләр (аның төбәк бүлекчәсе яки башка структур бүлекчәсе) белән тәкъдим ителгән район Советы депутатлары, депутат берләшмәләренә керәләр (фракцияләргә) (алга таба- фракция), әлеге статьяның 3 өлешендә каралган очрактан тыш. Фракция үз эченә, кандидатлар исемлегенә ярашлы составта сайланган, барлык депутатларны (депутатны) ала. Фракциягә шулай ук бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар һәм әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән, сәяси партияләр кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатлар (депутат) керә ала.

2. Фракцияләрнең эшчәнлек тәртибе, гамәлдәге законннарга ярашлы, район Советы регламенты белән билгеләнә.

3. Сәяси партиянең эшчәнлеге аның бетерелүе яки үзгәртеп корылуы сәбәпле туктатылган очракта, аның фракциясенең район Советындагы эшчәнлеге, шулай ук бу фракциядә депутатларның әгъзалыгы, юридик затларның бердәм дәүләт реерстрына тиешле язма кертелгән көннән туктатыла.

4. Сәяси партия (аның төбәк бүлекчәсе яки башка структур бүлекчәсе) тәкъдим иткән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутат, әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә, фракциядән чыгарга хокуклы түгел. Күрсәтелгән депутат ул сайланган кандидатлар исемлеге составында гына сәяси партия әгъзасы булырга мөмкин.

5. Фракциягә кергән һәм бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округына сайланган депутат, яки фракциягә кергән, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән, сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган депутат, үз фракциясенә кергән сәяси партиянең генә әгъзасы була ала.

6. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән, сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында үз фракциясе булган сәяси партиягә кергән депутат, әлеге фракциягә керә һәм аннан чыгарга хокуклы түгел.

7. Әлеге статьяның 4-6 бүлекләрендә каралган таләпләрне үтәмәү, депутат вәкаләтләрен туктатуга китерә.»;

40 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

41 статьяда:

1 өлешнең 4 пунктның а) пунктчасында «муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 өлешнең 4 пунктның а) пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга, «муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль берәмлек Башлыгы чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә һәм коррупциягә каршы тору максатыннан башка федераль законнар белән, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү, күрсәтелгән затлардан бәйсез булган шартлар тикшерүе тарафыннан “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25

декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылa икән.»;

43 статьяның 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

45 статьяда:

7 өлешнең 2 пунктының а) пунктчасында «муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 өлешнең 2 пунктының б) пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга, «муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

48 статьяның 3 пунктында:

тугызынчы абзацта "торак пункт территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук" сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзац белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«-тирә-яктагы мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый һәм мондый зыянны торак пункт милкендәге җир участоклары чикләрендә урнашкан территорияләргә карата бетерүне оештыра.»;

50 статьяны 7 пункт белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«7. Район Башкарма комитеты җитәкчесе чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә органнарын оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә һәм коррупциягә каршы тору максатыннан башка федераль законнар белән, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затлардан бәйсез булган шартлар тикшерүе тарафыннан "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылa икән.»;

51 статьяның 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

50 статьяны 7 пункт белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«Район Башкарма комитеты җитәкчесе:

1) Район Советы тарафыннан контрольдә тотыла һәм аңа хисап тота;

2) Район Советына үз эшчәнлеге һәм район Башкарма комитеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Район Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисапларны тәкъдим итә;

3) Район башкарма комитеты тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә.»;

54 статьяда:

2 пунктның 2) пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1.пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

VIII бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

85 статьяның 7 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

93 статьяны 2 пункт белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«2. Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру, “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелек) һәм муниципаль контроле турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законы белән көйләнә.”.

2. Әлеге карарны, дәүләт теркәвенә, гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә юнәлдерергә.

3. Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турындагы карарны, дәүләт теркәвеннән соң, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар, рәсми бастырылып чыкканнан соң, 6 статьяның 1 пунктындагы 41 пунктчасыннан кала, 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Район Советы рәисе И.И. Гозәеров